ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 107 от «20» 03 2023 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитетының 2021 елның
23 августындагы 274 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2022 елның 22 февралендәге 47 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 23 августындагы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 274 номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 нче Кушымтаның 2.5.1. пунктчасына түбәндәге эчтәлекле 5.1. пунктын өстәргә:

"5.1) капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен әлеге Кодексның 40.1 статьясында каралган очракта килештерү;".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М. Никифоровка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.М.Никифоров

0000013614